**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Вахитов авыл җирлеге Советы карары**

Җиңү бистәсе №173 28 июль 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 17 октябрьдә 56 номерлы карары «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен тезекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» (15.07.2013 №74-1, 17.02.2014 №87, 18.03.2014 №92, 18.08.2014 №109, 08.09.2018 №59, 19.02.2019 №122) карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Вахитов авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 17 октябрьдә 56 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен тезекләндерү кагыйдәләренә (15.07.2013 №74-1, 17.02.2014 №87, 18.03.2014 №92, 18.08.2014 №109, 08.09.2018 №59, 19.02.2019 №122 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.11.13 пунктта:
а) «каты кенкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;
б) «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.2. 2.11.16 пунктта «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.18 пункт белән тулыландырырга:
«2.11.18. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) тезекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, тезекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.Б. Бохарова